РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Шингальчинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423554, Нижнекамский район,
с. Шингальчи, ул.Школьная, 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районының
Шәңгәлче авыл җирлеге
Советы

423554, Түбән Кама районы,
Шәңгәлче авылы, Мәктәп урамы, 6

тел./факс (8555) 43-04-50, электронный адрес: Shingalchinskoe.Sp@tatar.ru,
сайт: www. shingalchinskoe-sp.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2024 ел № 13

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Түбән Кама муниципаль районының «Шәңгәлче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Шәңгәлче авыл җирлеге Советы карар бирә:

Аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнелә торган бурыч булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Р.Х.Сәлимов